Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

22 июль 2021 ел №64

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 12 маендагы 55 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларын алып бару һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе хакында»гы Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 23 октябрендәге ПУ-431 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2021 елның 25 июнендәге 09/13-09/3192 номерлы хокукый экспертиза бәяләмәсен, Әлмәт шәһәре прокуратурасының 2021 елның 13 июлендәге 02-08-02-777 номерлы күрсәтмәсен карап тикшергәннән соң,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 12 маендагы 55 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында»;

1.2. карарның 1 пунктында «Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнарында» сүзләрен «Әлмәт муниципаль районында» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. карарга 1 нче кушымтада:

1.3.1. «Гомуми нигезләмәләр» 1 бүлеге 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Муниципаль хезмәткәрләр реестрына кертелгән белешмәләр, федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләргә, ә башка очракларда – конфиденциаль характердагы белешмәләргә керә һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә якланырга тиеш.»;

1.3.2. «Реестрны алып бару» 2 бүлеге 2.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Муниципаль хезмәткәрләр реестрын формалаштыру һәм алып бару Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар һәм бүләкләр бүлегендә, Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр турындагы мәгълүматлар нигезендә, мәгълүмат системасында гамәлгә ашырыла.»;

1.3.3. «Реестрны алып бару» 2 бүлеге 2.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Муниципаль хезмәткәрләр реестрының формасы Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәткәрләре реестры формасына туры килә һәм мәгълүмат системасында урнаштырыла.»;

1.3.4. «Реестрны алып бару» 2 бүлеге 2.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Муниципаль хезмәттән азат ителгән муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көнне муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан төшереп калдырыла.

Муниципаль хезмәткәр үлгән (вафат) яисә муниципаль хезмәткәрнең хәбәрсез югалуы законлы көченә кергән, суд карары белән ул вафат дип игълан ителгән очракта, муниципаль хезмәткәр үлем (һәлак булу) көненнән яки суд карары законлы көченә кергән көннән соң килгән көннән соң, муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан төшереп калдырыла.»;

1.3.5. «Реестрны алып баруны контрольдә тоту» 3 бүлеге 3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып баруны Әлмәт муниципаль районы Башлыгы контрольдә тота. Контроль шәхси эшләрнең һәм аларның торышын тикшерү, муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси мәгълүматларын үз эченә алган белешмәләрне җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрындагы белешмәләр белән чагыштыру формасында гамәлгә ашырыла.

Мәгълүматларны чагыштыру факты тиешле актта чагылыш таба.»;

1.3.6. «Реестрдан мәгълүматлар бирү һәм реестрны саклау» 4 бүлеге 4.1 пунктында «рәсмиләштерелә алалар» сүзләрен «рәсмиләштерелә» сүзе белән алмаштырырга.

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов